**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«10» 02 2023 ел №478

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең Генераль планы проекты белән килешү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23-25 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Тукай муниципаль районы уставына, Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча 2021 елның 22 июнендәге халык тыңлаулар беркетмәләренә, Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча 2021 елның 22 июнендәге халык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләргә таянып

**КАРАР БИРӘ**

1. Татарстан Республикасының “Пространство мәгълүматлары фонды» ДБУ тарафыннан эшләнгән һәм 2021 елның 22 июнендә Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең Боерган, Колыш, Таулар, Туер авылларында халык тыңлауларында каралган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең Генераль планы проекты белән килешергә.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең Генераль планы проектың халык тыңлаулар беркетмәләре һәм халык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләр белән Тукай муниципаль районы Советына раслауга җибәрергә.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин